**Мөслим районы газетасы**
Татарстан Республикасы
**Чәршәмбе**
№ 60 (11312)
**19 август** 2020 ел
Газета 1931 елдан бирле чыга 16+

# Авыл утлары

**БЕЗ – МӨСЛИМЛЕЛӘР!**

**Сельские огни**

Район яңалыклары – безнең сайтта **www.muslumirc.ru** һәм социаль челтәрләрдә

# ТАССР байрагында Мөслимнең дә эзе бар

Кичә Мөслим ТАССРның 100 еллыгы флагы эстафетасын кабул итте. Район башлыгы Рамил Муллин байракка районыбыз гербы төшерелгән нашивка беркетте.




Андрей Митрофанов фотосы.

ТАССРга – 100 ел

**Лилия Шәймиева**

**Мөслим районында байракның республика буенча 23нче тукталышы. Киләсе тукталыш Лениногорск районында булачак. Россия регионнары һәм республикабыз буенча байрак ныклы, ышанычлы адымнар белән атлый.**

– Байрак эстафетасы 25 июльдә Татарстан башкаласында – "Казан" гаилә үзәге янындагы мәйданда башланган иде. Эстафетага Россия Һава флоты көненә багышланган "Мин күкне сайлыйм – 2020" авиация бәйрәмендә старт бирелде. Парашютчыларның күрсәтмә чыгышлары, гражданнар һәм ерак авиация һава суднолары, пилот төркемнәренең очышлары күрсәтелгән бәйрәмдә 30лап һава судносы катнашты, – ди байрак сакчысы Данил Ясельский.

Татарстан Россия төбәкләре лидерлары арасында сынатмый. Һәр районда ТАССР флагын зурлап каршы алалар. 45 муниципаль районны урап чыкканнан соң, 30 август көнне байрак Казанга әйләнеп кайтачак. Республика көнендә ТАССР байрагы башкаланың милли музеена куелачак.

– Бу – истәлекле көн. ТАССР байрагында Мөслим районы да үз эзен – символикасын калдырды. Байракның юлы дәвамлы булсын! ТАССРның бер гасырлык юбилее – әбибабайларыбызның үткәне, әти-әниләребезнең тормышы, бүгенгебезнең көзгесе, – диде район башлыгы.

Мөслимгә бу көнне яшьләр автобусы да килде. "Яшьләр вакыты" исемле яшьләр туры республиканың бөтен районнарында үтәчәк. Аның максаты – 14-35 яшьлек яшьләр белән очрашу.

– Яшьләр автобусының Мөслимгә икенче мәртәбә килүе. Узган ел бертөркем республика яшьләре Мөслимебездә кунак булып, яшьләр тормышын өйрәнеп киткән иде. Алар уздырган лекцияләр бик кызыклы. Укучылар, яшьләр уңышлы проектлар белән бик кызыксына. Быел Мөслим яшьләре үзләре әзерләгән 15 проект эшен тәкъдим итте. Алар һичшиксез тормышка ашар, дип уйлыйм. Чөнки егет-кызларыбыз бик сәләтле,– ди район Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль-мәдәни мәсьәләләр буенча урынбасары Марина Бәдретдинова.

Идеяңне тормышка ашырудан, хыялны чынбарлык итүдән курыкмаска кирәк. Моның өчен теләк һәм мөмкинлекләрне дөрес файдалана белү мөһим. Кыю яшьләр, мөмкинлектән файдаланып, "Мизгел" яшьләр үзәгендә проектлар яклады. Гореф-гадәтләрне саклау, яшьләрнең ялын кызыклы итү, спортны үстерү һәм башка юнәлешләрдә 15 проект тәкъдим ителде. Аларның төрле темаларга булуы сөендерә. Районның яшьләр белән эшләү һәм мәгариф бүлекләре, "Мизгел" яшьләр үзәге һәм актив яшьләр ТР Яшьләр эшләре министрлыгының Рәхмәт хатлары белән бүләкләнде. "Яшьләр медиаүзәге" проекты грантка лаек булды.

## Хәбәрләр

### Авыл җыеннары башланды

**Район җитәкчелеге катнашында узган чарада җирлектә башкарылган һәм алда торган эшләр турында сүз барды.**

Җирлек башлыклары үзара салым акчасының кайсы өлкәләргә бүленүен, су белән тәэмин итү, авыл урамнарын яктырту, янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү, шәхси ихаталарны хуҗасыз этләрдән саклау һәм башка мәсьәләрләгә тукталды. Вәрәшбаш, Симәк, Крәш. Шуран, Исәнсеф авыл җирлекләрендә үткән җыеннарда халык үзләрен борчыган сорауларга җаваплар да алды.

### Халык санын алу күчерелә

**Коронавирус статистика мәгълүматларын алуга үзгәрешләр кертте.**

Бөтенроссия халык санын алуның төп этабы 2020 елның октябрь аенда узар дип планлаштырылган иде. Эпидемиологик хәл бәйле Росстат халык санын алуны 2021 елга күчерергә тәкъдим итте. РФ хөкүмәте карары нигезендә Бөтенроссия халык санын алу 2021нче елның 1-31 апрель көннәрендә узачак.

### Балалар да эшли

**Җәй дәвамында районның хезмәт һәм мәшгульлек үзәге аша 125 бала эш урыннары белән тәэмин ителгән.**

Хезмәт чирегендә 14-18 яшьлек укучылар "Төзекләндерү һәм яшелләндерү" унитар предприятиесендә, Мөслим кирпеч заводында, икмәк кабул итү һәм эшкәртү предприятиесендә, "Август-Мөслим" агрофирмасында, Иске Карамалы, Баек, Баланлы, Симәк, Крәш. Шуран авыл җирлекләрендә, Актаныш районының "Әнәк" агрофирмасында эшләгән. Һәр балага минималь хезмәт хакыннан да аз булмаган суммада (12130 сум) хезмәт хакы, моңа өстәп хезмәт һәм мәшгульлек үзәге аша 2250 сум күләмендә өстәмә акча түләнгән.

## Һава торышы

**Чәршәмбе** 19.08 +8 **+13**

**Пәнҗешәмбе** 20.08 +8 **+15**

**Җомга** 21.08 +11 **+17**

**Шимбә** 22.08 +10 **+18**

«Авыл утлары»
№ 60 (11312) | 19 август 2020 ел

Яңалыкларны беренче булып
www.muslumirc.ru сайтында укыгыз

Бу көнне Мөслимдә

**Әлеге рубрикадагы язмалардан төрле елларда "Авыл утлары" газетасында яктыртылган вакыйгалар, яңалыклар хакында белерсез.**

## 1985 ел

**22 август**
**Олы бүләк тапшырылды**

Коры сөт заводы – матур эшләре белән танылган алдынгы предприятиеләрнең берсе. Аның даны районыбыздан еракта да таралды. Коллектив өчен агымдагы бишьеллык аеруча истәлекле булды. Узган елларда да завод тугыз мәртәбә Бөтенсоюз һәм РСФСР күләмендәге күчмә Кызыл байракларга лаек булган иде. Һәм менә чираттагы хезмәт казанышы: беренче яртыеллык йомгаклары буенча предприятие РСФСР Ит-сөт промышленносте министрлыгы һәм азык промышленносте эшчеләре профсоюзы үзәк комитетының күчмә Кызыл байрагы һәм беренче акчалата премия белән бүләкләнде.

**24 август**
**Август педсоветы**

22 августта Мөслим урта мәктәбендә укытучыларның август киңәшмәсе үзенең эшен башлады. Бу көнне эш секцияләрдә дәвам итте. Кичен яшь укытучылар район җитәкчеләре, педагогик хезмәт ветераннары белән очрашып, район тормышы белән таныштылар.

23 август көнне район культура йортында киңәшмәнең пленар өлеше булды. Быел районыбызның укытучылар коллективын югары уку йортларыннан, техникумнардан һәм училищелардан килгән 36 яшь белгеч тулыландырды. Аннары укытучылар предмет секцияләренә бүленеп эшләделәр. Кичен укытучыларга багышланган концерт булды.

Олы педсовет бүген үзенең эшен дәвам итә.

**"Кызыл Октябрь" колхозы – җиңүче**

1984-1985 еллардагы кышлату чорында терлек кышлатуны уңышлы үткәрү, терлекчелек продуктлары җитештерү һәм хәзерләүне арттыру өчен барган Бөтенсоюз социалистик ярышында районыбызның "Кызыл Октябрь" колхозы җиңүче дип табылды һәм ул КПСС Үзәк Комитеты, СССР Министрлар Советы, ВЦСПС һәм ВЛКСМ Үзәк Комитетының Мактау грамотасына лаек булды.

**Медаль тапшырылды**

Сергей хезмәтчел гаиләдә үсте. Әтисе Василий – механизатор. Әнисе озак еллардан бирле терлекчелектә эшли. Хәрби бурычын үтәгәч, Сергей Ларчев туган ягына кайтты. Һәм менә узган елның августыннан бирле ЮМЗ-6 тракторын идарә итә. Бу көннәрдә терлек азыгы хәзерләүдә катнаша.

Күптән түгел егет тормышында истәлекле вакыйга булды: аңа район хәрби комиссариатында "Сугышчан хезмәтләре өчен" медале тапшырдылар.

*Сәхифәне Мөнирә Арсланова әзерләде.*

# Хәйрия марафоны игелеккә өнди

14 август көнне "Мәктәпкә әзерләнергә ярдәм ит!" акциясе кысаларында хәйрия марафоны узды.

Игелек

**Лилия Шәймиева**

**Анда районның 34 оешма-предприятиесе, райондашларыбыз акчалата ярдәм күрсәтте.**



Лилия Шәймиева фотосы.

– Әлеге чара ел саен Белем көненә бер ай кала старт ала. Быел да марафоннан җыелган средстволар аз тәэмин ителгән, күпбалалы, ялгызы бала тәрбияләүче әти-әниләргә бүлеп биреләчәк. 30 балага мәктәп кирәк-яраклары өчен сертификатлар тапшырылды инде. Мондый сертификатлар йөздән артык гаиләгә биреләчәк, – диде район Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль-мәдәни мәсьәләләр буенча урынбасары Марина Бәдретдинова.

Игелек, хәйриячелек, мәрхәмәтлелек кебек төшенчәләр яшәү рәвешебезгә әйләнде. Җирлегебездә унберенче тапкыр узучы хәйрия акциясендә катнашучыларның актив булуы да шуңа ишарәли. Татарстан Республикасының беренче президенты башлангычы белән нигез салынган чараның дәвамлы булуы сөендерә.

– Яңа уку елын һәр баланың яңа киемнәрдән, яңа әсбаплар белән үткәрәсе килә. Беренче сыйныфка баручылар өчен бу көн аеруча истәлекле. Ләкин бөтен кешенең дә мөмкинлекләре бер түгел. Оешмалардан, шәхси эшмәкәрләрдән һәм физик затлардан кергән акча бергә туплана. Шул средстволардан һәр балага 2 мең сумлык сертификат бирелә. Бу сертификатлар белән район үзәгендәге кием-салым, канцелярия товарлары кибетләреннән кирәкле әйберләрне алырга була, – ди район мәгариф идарәсе җитәкчесе Рафаэль Демидов.

Әйе, арабызда ишле, матди яктан аз тәэмин ителгән гаиләләр дә, ялгызы гына ул-кызларын үстерүче әти-әниләр дә бар. Андый гаиләләргә адреслы ярдәм күрсәтү өчен мәктәп директорлары һәм укытучылар социаль яклау бүлеге хезмәткәрләре белән берлектә мохтаҗ балалар исемлеге төзегән.

– Хәйрия акциясендә катнашучылар – олы йөрәкле, мәрхәмәтле затлар. Башкалар турында уйлау, игелекле гамәлләр кылу өчен тирә-юнендәгеләрнең борчуларын йөрәгең аша уздырырга, шатлыкларына ихластан сөенә белергә кирәк. Мәктәпкә әзерләнү чоры акчага кытлык кичергән гаиләләр өчен дә күңелле мизгел булып истә калсын өчен уздырыла әлеге чара. Матур костюм-чалбар, мәктәп сумкасы, яңа итәк-блузка, ялтырап торган түфли – һәр баланың хыялыдыр ул. Без дә шушы ярдәмне алдык. Марафонны оештыручыларга да, ярдәм күрсәткән райондашларыбызга да зур рәхмәт, – диде райондашыбыз Илүсә апа.

Игелек марафоны 25 августка кадәр дәвам итәчәк. Теләгән һәркем социаль яклау бүлегендә булдыра алган кадәр матди ярдәм калдыра ала. "Агромастер" җитештерү компаниясе җитәкчесе быел да саллы ярдәм күрсәтте. Марафонга кушылып, Илгиз Исламов 100 мең сум акча бирде. Бу средстволар, 10ар мең сумлык сертификатлар итеп, 10 балага тапшырылачак. Район электр элемтәсе бүлеге җитәкчесе Марсель Әһлиев биш баланы уку кирәк-яраклары тутырылган сумка белән сөендерде. Игелек акциясенә район авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе, мәгариф идарәсе, казначылык, район мәктәпләре һәм балалар бакчалары, инженерлык челтәрләре, газ идарәсе, Мөслим урманчылыгы, массакүләм спорт һәм мәдәни чаралар дирекциясе беренчеләрдән булып кушылды. Тамчыдан күл җыела, ди. Игелекле гамәлләребез белән ешрак сөендерергә язсын!

# Урак алдынгылары

**Беренче графа – комбайнчының исем-фамилиясе, икенче – хуҗалыклар, өченче – урак башыннан эш күрсәткече (центнерларда).**

*Мәгълүматлар 18 августка.*

**"Нью-Холланд", "Торум-750", "Тукано" комбайннарында**

| | | |
|---|---|---|
| Максим Тазов | "Намус" а/ф | 30256 |
| Сирин Хуҗин | "Туган як" а/ф | 21618 |
| Евгений Үтәгәнов | "Туган як" а/ф | 19299 |
| Динар Солтанов | "Туган як" а/ф | 17817 |
| Раил Мәүләвиев | "Туган як" а/ф | 16726 |
| Марсель Үтәгәнов | "Туган як" а/ф | 13836 |
| Руслан Кәлимуллин | "Август-Мөслим" ҖЧҖ | 12420 |
| Ринас Хафизов | "Август-Мөслим" ҖЧҖ | 11951 |
| Айдар Галләмов | "Туган як" а/ф | 10682 |
| Наил Дәүләтгәрәев | "Август-Мөслим" ҖЧҖ | 10362 |
| Глүс Мадышин | "Август-Мөслим" ҖЧҖ | 10261 |
| Ришат Гыйльфанов | "Август-Мөслим" ҖЧҖ | 9893 |
| Дамир Гәрдисламов | "Август-Мөслим" ҖЧҖ | 9711 |
| Олег Ермолаев | "Август-Мөслим" ҖЧҖ | 9441 |
| Нияз Хәйбрахманов | "Август-Мөслим" ҖЧҖ | 9020 |
| Динар Муллин | "Август-Мөслим" ҖЧҖ | 8889 |

**"Полесье", "Кейс", "Акрос-585" комбайннарында**

| | | |
|---|---|---|
| Данил Нәгыймов | "Туган як" а/ф | 19208 |
| Раил Әхмәтшин | "Намус" а/ф | 18955 |
| Илнар Игбаев | "Намус" а/ф | 17763 |
| Руслан Шакиров | "Намус" а/ф | 13144 |
| Илмир Җамалетдинов | "Туган як" а/ф | 12525 |
| Руслан Вәлиев | "Исламов" КФХ | 9330 |
| Фаил Гыйзетдинов | "Исламов" КФХ | 9028 |
| Фәнис Минһаҗев | "Исламов" КФХ | 8638 |
| Ленар Идиятуллин | "Намус" а/ф | 8457 |
| Владислав Ермолаев | "Исламов" КФХ | 8096 |
| Рифгать Мөхәмәтов | "Исламов" КФХ | 7571 |
| Роберт Абдуллин | "Намус" а/ф | 7508 |
| Ринал Хаҗиев | "Исламов" КФХ | 7473 |
| Радик Галләмов | "Туган як" а/ф | 7449 |
| Рифат Фазлыев | "Авзалов" КФХ | 5195 |

**"ЕС-1" ургычында (гектарларда)**

| | | |
|---|---|---|
| Юрий Григорьев | "Нуретдинов" КФХ | 780 |
| Виталий Сиваков | "Авзалов" КФХ | 200 |





Фото – "Мөслим-информ" архивыннан.

2020нче елның 13 сентябрендә узачак Татарстан Республикасы Президентын сайлауларына кандидатларның агитация материаллары

**Традицияләргә тугрылык. Киләчәккә ышаныч!**

11-13 сентябрь – Татарстан Президентын сайлаулар

Рөстәм Миңнеханов



Публикуется бесплатно в соответствии с частью 1 статьи 62 избирательного кодекса РТ от 07.05.2007 №21-ЗРТ. Предвыборный агитационный материал предоставлен зарегистрированным кандидатом на должность Президента Республики Татарстан Рустамом Нургалиевичем Миннихановым.

# Казаннан җәяү кайткан

Фантастик эшләре, көтелмәгән гамәлләре белән шаккатырып, Гиннесның рекордлар китабына кергән кешеләр аз түгел. Райондашыбыз Рөстәм Бухаринны да әлеге китапка кертеп булыр иде.

Шөгыль

**Лилия Шәймиева**

**Алты көн эчендә Казаннан Мөслимгә җәяү кайткан райондашыбыз. Без Рөстәмне Ташлыяр авылы янында каршы алдык. Арып, аякларын ял иттерү өчен туктаган вакыты иде Рөстәмнең.**



Лилия Шәймиева фотосы.

– Казаннан 8 август көнне иртәнге сәгать дүрттә чыгып киткән идем. Машина юлыннан кайттым. 64 километр юл узгач, Лаеш районының Имәнкискә авылы янында ял итәргә туктадым. Шушы авыл кешесе күреп, үзләрендә кунарга чакырды. Кадет мәктәбендә балаларга физкультура дәресләрен укытучы Тәлгать абый үзе дә экстремаль спорт төрләрен яратучы кеше булып чыкты. Төн кунып, иртән иртүк юлга кузгалдым. Юлда начар кешеләргә юлыкканым юк. Җәяү барганны күреп, туктап, илтеп куярга тәкъдим итүчеләр дә, кунакка чакыручылар да, минем белән фотога төшүчеләр дә булды, – дип искә ала Рөстәм.

Мөслимгә кайтып җиткәнче Рөстәм юлда биш төн кунган. Икенче төнен ул Чистай районында, чишмә янында палатка корып уздыра, чираттагы куну урыны Яңа Чишмә районы отелендә булган. Әлеге кунакханәгә егетне башта кертергә теләмәгәннәр. Ничә көн юлда булып, сакал-мыегы җиткән, төнлә ял урыны сорап кергән райондашыбыз шик уяткан, күрәсең. Акча тәкъдим иткәч, отель хуҗалары кунарга керткән.

– Күпчелек урман буенда яки посадкаларда төн уздырырга тырыштым. Иртән чык аякны юешләмәсен дисәң, юлдан читкә китәргә ярамый. Юл хәлне ала. Чишмә суы организмны яңадан торгыза. 60 километрлап ара узган саен туктап, ял иттем. Дүртенче тукталышым – Әлмәт районының Кузайкино авылы янында, соңгысы Әлмәт-Сарман чиге янындагы посадкада булды. Иң мөһиме – кыргый этләр килеп чыкмасын! Алардан котылу юк дияргә була. Кыргый хайваннардан саклану өчен үзем белән җәнлекләрне куркыта торган шартлаткычлар йөртәм, – ди Рөстәм.

Бу Рөстәмнең беренче сәяхәте генә түгел. Тәүге тапкыр ул 2013 елда башкаладан Мөслимгә велосипедта кайта. Ул вакытта Мөслимгә 22 сәгать эчендә кайтып җитә.

Рөстәм йөри бит әле дип, Казанга җәяүләп чыгып китә күрмәгез тагын! Егет кечкенәдән спорт белән шөгыльләнә. Шуның өстенә көчле рухлы, максатчан, үҗәттә ул. Казан-Мөслим арасын җәяү узу өчен махсус спорт киеме дә булырга тиеш. Җәяү сәфәр чыгуының максаты – үз көчен сынап карау. Рөстәм узган ел да Казаннан җәяүләп кайтырга чыккан булган.

– Әзерлексез булу һәм дөрес атламау сәбәпле Әлмәт районына җиткәндә аякларым алҗады, аякларымда басып тора алмый башладым. Быел менә максатыма ирештем, – ди райондашыбыз.

Рөстәм Бухарин Казан шәһәрендә яши, медицина җиһазлары белән сату итә. “Эшмәкәрләр төркемендәге һәркем үз алдына билгеле бер максат куя”, – ди Рөстәм. Кайсы – Эльбрус, кемдер – Эверест тавына менә. 15 танышы, 50 мең сум түләп, Эльбруска менгән. Дөньяның иң биек тавына күтәрелү 7 миллион сумга төшә, ди. 36 яшьлек Рөстәм, кызыксынучы көчле булгач, Ык елгасының су башын да күреп кайткан. Ык Бишбүләк районының Игнашкино авылыннан, ике каен арасындагы кечкенә сазлыктан башлана! Шуннан 120 км җәяү кайткан райондашыбыз. Елга киңәеп киткән җирдән сәяхәтен резин көймә белән дәвам иткән. Барлыгы 340 км юл уза ул. Шуның 120 километрын – җәяүләп, 220 километрны – көймәдә ишеп.

– Һәр әти-әни баласы өчен борчылып яши. Ничә яшьтә булса да, сабый әле ул безгә. “Исән-имин кайтып җитсен”, – дип телибез. Ишекне ачып кергәнче энә өстендә утырган кебек инде. Сәяхәте белән социаль челтәрләр аша таныштырып бара Рөстәм. Шуннан аның кайда, нинди маршрут белән баруыннан хәбәрдар без. Берсендә, инстаграмда кофе белән шоколад сурәтен куйгач, ашарына да юк икән, дип борчылдык. Ә ул, безне тынычландырып: “Шоколад энергия бирә, ник кайгырасыз?” – дип елмая. Рөстәм Европага велосипед белән бару турында хыяллана, – ди Рөстәмнең әти-әнисе Валерий абый белән Гөлчәчәк апа.

Рөстәм атаклы сәяхәтче, ат караучы Руслан Верин белән элемтәдә тора. Икәү киңәшләшәләр, яңа идея-планнар белән яналар. Руслан турында хәтта Согуд Гарәбстаны шәехе дә хәбәрдар икән. Шәех Рөстәмне җәяүләп яки велосипедта кунакка килергә чакырган. Ниятенә керсә, барыр да! Уйлаганын эшли, максатларына ирешә торган егет ул!

«Авыл утлары»
№ 60 (11312) | 19 август 2020 ел

Яңалыкларны беренче булып
www.muslumirc.ru сайтында укыгыз

# Укытучыларга ихтыяҗ зур

85 районташыбыз педагогик уку йортларында белем ала. Алар, җирлегебезгә эшкә кайткан очракта да, районның укытучыларга булган ихтыяҗын канәгатьләндерә алмаячак.



Фото – "Мөслим–информ" архивыннан.

**Римма Афзалова**

**Яңа уку елына санаулы гына көннәр калып килә. Район мәгариф идарәсе җитәкчесе Рафаэль ДЕМИДОВ белән әңгәмәбез узган уку елы нәтиҗәләре һәм алда торган бурычлар турында.**

**– Рафаэль Тимофеевич, иң элек узган уку елы нәтиҗәләренә тукталыйк әле.**

– Белем бирү сыйфатын бәяләүнең төп инструментларның берсе – чыгарылыш сыйныф укучыларының дәүләт йомгаклау аттестациясе. 2020 елда дәүләт йомгаклау аттестациясенең БДИ форматында 99 чыгарылыш сыйныф укучысының 86сы катнашты. Алар ун фәннән имтихан тапшырдылар. 2019 ел белән чагыштырганда, имтихан тапшыру өчен җәмгыять белеме, тарих, инглиз теле фәннәрен сайлаучылар саны артты. Быел тарих, инглиз теле, җәмгыять белеме фәннәреннән уртача балл 2019 ел күрсәткечләреннән югары. Узган ел бу фәннәр тәнкыйтькә эләккән иде. Биш фәннән (физика, информатика, химия, биология, җәмгыять белеме) имтихан бирүче балалар арасында минималь баллны җыя алмаучы укучылар да булды. Химия, инглиз теле буенча район күрсәткечләре республиканың уртача күрсәткечләреннән югарырак. 33 чыгарылыш класс укучысы БДИны югары балларга тапшырды. Мөслим политехника техникумын быел 34 укучы тәмамлады, шулардан 12се Казан дәүләт аграр университетына укырга керде. 2020-2021 уку елына 80 студент кабул ителәчәк.

**– Мәгариф учреждениеләренең яңа уку елына әзерлеге ничек?**

– Белем бирү оешмаларына капиталь ремонт үткәрү программасы нигезендә Баланлы төп гомуми белем бирү мәктәбендә ремонт бара. "Үсеш ноктасы" проекты кысаларында район үзәгендәге өч мәктәпкә һәм Михайловка урта мәктәбенә ремонт үткәрү өчен республика бюджетыннан акча бүленде. Әлеге мәктәпләрдә технология, информатика һәм тормыш иминлеге нигезләре фәннәре кабинетларына җиһазлар кайтарылачак. Быел Г.Тукай исемендәге Мөслим, Түбән Табын, Сал.-Мухан мәктәпләрендә дә ремонт эшләре барды. Район бюджеты, спонсорлар хисабына белем бирү учреждениеләрен җиһазлар белән тәэмин итү дәвам итә. Район үзәгендәге мәктәпләр яңа парталар, физика, химия, лингофон кабинетлары, интерактив җиһазлар белән тулысынча тәэмин ителде.

**– Рафаэль Тимофеевич, мәгариф учреждениеләренең кадрлар белән тәэмин ителешен ничек бәялисез?**

– Бүген мәктәпләрдә пенсия яшендәге 38 укытучы эшли. Өч елдан 49 укытучы лаеклы ялга чыгачак. Районда 35 яшькә кадәрге укытучылар саны 8 процент кына (41 кеше) тәшкил итә. Быел бер яшь белгеч "Безнең яңа укытучы" республика грантына ия булды. Яңа уку елында яшь белгечләр сафын алты укытучы тәрбияче тулыландырачак. Былгы чыгарылыш сыйныф укучылары арасыннан 11 бала югары педагогик уку йортларына гаризаларын тапшырды. Узган уку елында укытучы һөнәрен сайларга теләүчеләр Г.Тукай исемендәге Мөслим урта мәктәбеннән күбрәк булсалар, быел лицейдан – дүрт, гимназиядән – өч, Мөслим урта мәктәбеннән – ике һәм Күбәк, Тат. Бүләр мәктәпләреннән берешәр бала педагогик уку йортларына максатчан юллама алды. Шулардан дүрт укучы стипендиаль ярдәм күрсәтү проекты буенча педагогик белгечлекләргә бирелүче грантка лаек булды. Педагогик уку йортларында бүгенге көндә 85 укучы укый. Ләкин алар, укуларын тәмамлап, җирлегебезгә эшкә кайткан очракта да, районның педагогларга булган ихтыяҗын канәгатьләндерә алмаячак.

**– Бүген милли мәгарифкә зур игътибар бирелә. Безнең районда бу юнәлештә эш ничек оештырылган?**

– Милли мәгариф үсешен тәэмин итү – мәгариф идарәсенең төп эшчәнлек юнәлешләреннән берсе. Районда 98,71 процент укучы туган тел дип – татар телен, 1,28 процент мари телен сайлады. 13 гомуми белем бирү учреждениесендә укыту – татар телендә, бер мәктәптә башлангыч сыйныфларда мари телендә алып барыла. Г.Тукай исемендәге Мөслим урта мәктәбенең ике беренче сыйныфында укытуны татар телендә оештырдык. Мөслим районының милли мәгарифне үстерү концепциясен тормышка ашыру планы – юл картасы эшләнде һәм шуның нигезендә максатчан эш алып барыла. Туган телебезне, тарихыбызны өйрәтү, төрле милләт халыкларының дуслыгын тәэмин итү, яшь буында милли үзаң формалаштыру – милли мәгариф алдында торган әһәмиятле бурычлар. Балаларда туган телгә мәхәббәт тәрбияләү, китап укырга күнектерү, яшь каләм тибрәтүчеләрне үстерү максатында "Китап корты" проекты тормышка ашырыла.

# Барысы да – балалар өчен

**Соңгы өч елда мәктәптән тыш эшләр үзәгендә түгәрәкләр нигезендә техник юнәлештә оештырыла. Биредә балалар бик яратып йөри торган робототехника, инженерлык лабораториясе, IT-программалаштыру, фото-видеостудия, башлангыч техник модельләштерү һәм башка берләшмәләр эшли.**



Фото – мәктәптән тыш эшләр үзәге архивыннан.

Ел дәвамында өстәмә белем бирү педагоглары балалар белән район, республикакүләм бәйгеләрдә катнашып, призлы урыннар яулады. Робототехника түгәрәгендә шөгыльләнүчеләр Аяз Бәдртдинов җитәкчелегендә Мамадыш шәһәрендә узган "Техноигры 2.0" фәннитехник квестта икенче урынга лаек булды. Яшь фотосөючеләр Эльза Шәймәрданова белән берлектә "Юность России" Бөтенроссия бәйгесенең республика этабында "Макро" номинациясендә – икенче, "Репортаж" номинациясендә өченче (җитәкчесе Андрей Митрофанов), "Анималистика" номинациясендә (җитәкчесе Аяз Бәдртдинов) икенче урынны алдылар. "Техник модельләштерү" (педагог Илшат Закиров) һәм "Робототехника" (педагог Аяз Бәдртдинов) номинацияләрендә өченче урынга чыктылар. Традицион "Искиткеч вожатый", "Брейн-ринг", чаңгы туризмы ярышларында, "Чиксез балачак" халыкара фестиваленең кул эшләре, рәсем, театр бәйгеләрендә, төрле акцияләрдә республика буенча призлы урыннарга ирештек.

Тагын бер эш юнәлешебез – балалар хәрәкәте эшчәнлеген оештыру. Һәр мәктәптә актив укучылар бар. Үзара тәҗрибә уртаклашу, төрле идеяләр тәкъдим итү максатыннан алар белән очрашулар оештыруны гамәлгә керттек. Атнага ике тапкыр кич укучылар белән төрле өстәл уеннары уйнау, кино карау, чәй өстәле артында фикер алышу мөмкинлеге тудырылды. Профориентлашу айлыгында балалар, төрле оешма-предприятиеләрдә очрашуларда булып, үзләрен кызыксындырган сорауларга җаваплар алдылар. Мөслимдә узган ТР балалар оешмасы советы форумы да укучыларда зур кызыксыну уятты.

Балаларның җәйге ялларын оештыру да мәктәптән тыш эшләр үзәге җаваплылыгында. Һәр елны мәктәп яны лагерьларында – 234, хезмәт һәм ял лагерьларында – 125, "Урман иле" ял һәм сәламәтләндерү лагерендә 220 бала вакытларын файдалы һәм күңелле итеп уздыра. Кызганычка каршы быел билгеле сәбәпләр аркасында балаларның ялын оештыру мөмкин булмады. Мәктәп яны лагерьлары көзге һәм кышкы каникулларга күчерелде. "Урман иле" лагеренда киләсе елда ремонт эшләре планлаштырыла. Ашханә, медпункт, йокы корпусларының эчке өлеше дизайнерлар тәкъдим иткән проект нигезендә үзгәртеләчәк, территория заман таләпләренә туры китереп төзекләндереләчәк, велосипед юллары ясалачак. Шулай ук лагерьга баручы юлга асфальт җәю, машина кую урыннары булдыру да каралган.

Башкарган һәр эшебез балаларның киләчәге – матур, яллары – күңелле, буш вакытлары файдалы булсын өчен эшләнә.

**Наилә Сәлахова,
мәктәптән тыш эшләр
үзәге методисты.**

# Табигать яратучы Эльвир

Райондашыбыз Эльвир Солтанов табигатькә гашыйк. 15 яшьлек егет дару үләннәре җыя.

**Лилия Шәймиева**

**Быел күпләп иван-чәй, мәтрүшкә, бөтнек һәм тагын бик күп төрле дару үләннәрен җыйган егет.**

– Кечкенәдән ук аяк астындагы һәр бөҗәкне кызыксынып күзәтә иде улыбыз. Бер генә үлән-яфракны да игътибарсыз калдырмады ул. "Бу нәрсә? Ә монысы ничек оча? Нәрсә ашый? Кайда яши?" кебек бихисап сораулар белән ялыктыра иде кайчак. Җәй саен Гена абыйсына ярдәмгә авылга кайта. Җәйге каникулны ул рәхәт һәм файдалы итеп үткәрә белә, – ди Эльмира Солтанова.

Эльвир – Яңа Усы авылында күпләп умарта тотучы Геннадий Кондратьевның энекәше. Умартачы һөнәренә мәхәббәт тә абыйсыннан күчкәндер, мөгаен. 10 яшеннән Гена абыйсына булыша егет. Бүген үзенең дә ике баш умартасы бар.

– Бу җәйдә "ловушка"га тагын берсе эләкте! Икәү булдылар дип сөенәм хәзер. Тугыз банка – 27 литр бал алдым. Дару һәм чәй үләннәрен аерым кап-савытларга тутырып, исемнәрен язып куям. Сатып, акча да эшлим, үземчә бизнес инде бу. Егет һәм кызларга шуны әйтәсем килә: иренмәсәң, һәрнәрсәне башкарып чыгарга була. Табигать дөньясында без белмәгән әллә нинди серләр, могҗизалар бар. Аларны гомер буе өйрәнсәң дә, бөтен нечкәлекләренә төшенеп бетә алмыйсың. Яр Чаллы шәһәрендә яшәсәм дә, әнием шушы авылныкы булгач, Яңа Усыга очып диярлек кайтам. Үземне Мөслим егете дип саныйм, – ди Эльвир.

Гаиләдә Эльвир җыйган иван-чәйне генә эчәләр. "Аның исе дә дәвалау сәләтенә ия. Шампуньнарыбыз да табигый. Эльвир шампуньны ромашкадан үзе ясый. Чәчләр куе һәм ефәк кебек була. Без белмәгәнне дә белә улым, зиһене-ушы шаккатмалы. Химия дәреслекләрен бер ел алдан укып бара, – ди әтисе Зинфир, улы белән горурланып.

Җир-ананың сулышын тоеп, бал кортлары белән әвәрә килеп яшәгәнгәме, үзе дә бал корты шикелле уңган, җитез, тиктормас Эльвир. Үҗәтлеге булган – максатына ирешкән, диләр. Эльвир хыялларын җилкән итеп яши.



Лилия Шәймиева фотосы.

## Тәҗрибәле Динар



Әлфинур Ногманова фотосы.

**Лилия Шәймиева**

**Каенсаз авылы егете Динар Муллин – "Август-Мөслим" агрофирмасының уңган механизаторларының берсе. Яшь булса да, әлкәннәр тәҗрибәсе бар үзендә.**

Мөслим аграр көллиятендә укып тракторчы-машинист таныклыгын ала. Хәрби хезмәтне Хабаровск өлкәсендә үтә. Язмышын авыл хуҗалыгы белән бәйләү теләге кечкенәдән була егеттә. Алдынгы тракторчы булган әтисе улында җир-анага мәхәббәт тәрбияли. Хезмәт юлын "Вамин" җәмгыятендә тракторчы булып башлый Динар. 2010 елның коры җәе була ул. "МТЗ-1221" тракторында Пермь якларына китеп, терлек азыгы әзерли. 50 көн дәвамында күпьеллык үлән ура, печән әзерли. Үҗәтлеге ташып торган егетне җәйге челләдә, корылык та куркытмый.

Бу сезонда райондашыбыз "Клаас" тракторы базасындагы "Барго" чәчү комплексында эшли. Ел да кыр батыры буларак хөрмәтләнә уңган егет. Быелгы урыпҗыю чорында да сынатмаска исәбе. Урып-җыю башланганнан бирле агрофирма басу-кырларыннан 10 мең центнердан артык ашлык суктырып алды Динар. Сенаж ташуга да чыгачак. 30 тонна сыйдырышлы "Флигель" арбасы белән "Клаас" тракторында башкарылачак бу эш.

– Эштән курка торган чак түгел. Эшләгән кешенең акчасы да мул дан, хөрмәте дә зурдан була. Авыл егетләре шәһәргә китеп, таш-пулатлар арасында калып, туган җирләренә хыянәт итмәсеннәр иде. Җир кешесе өчен бөтен мөмкинлекләр дә тудырылган заманда яшибез. Уңайлы техникада туган якның басу-кырларын иңләү – иң зур бәхеттер, мөгаен! – ди Динар.

## Яшьләр ничек ял итә?

**"Яшьләр авылда калмый" дисәләр дә, җәйге ялларын егет-кызлар нигездә авылда үткәрә. Аңлашыла: әтиәниләренә, әби-бабаларына булышалардыр. Ә ял вакытларын яшьләр ничек үткәрә? Әлеге сорау белән без егеткызларның үзләренә мөрәҗәгать иттек.**

**Динар, 21 яшь:**
– Көндез – эштә, кичләрен дуслар белән очрашабыз, җыелу урыны – парковка. 1-2 сәгать сөйләшеп утырабыз, кайчак Яр Чаллыга барып кайтабыз. Анда дискотекага бара идек. Пандемиягә кадәр кинога йөри идек. Мөслимдә Ык буена төшәбез, велосипедта йөрибез. Ял көннәрендә балыкка төшәбез, шашлык пешерәбез.

**Марсель, 35 яшь:**
– Авылда нишлисең инде, дуслар белән очрашып, сөйләшеп утырабыз, я булмаса, өйдә телевизор карыйбыз, интернетта утырабыз. Ялларда берәр шәһәргә барып кайтырга була. Анда барыр урыннар күбрәк.

**Айгөл, 18 яшь:**
– Коронавирус таралганчы кафеда утыра идек. Хәзер, дуслар чыкса, урамда йөрибез. Өйдә булсам, сериаллар карыйм, нәрсә дә булса эшләгән булам. Элек "Мизгел" яшьләр үзәгендә дискотекалар була иде, хәзер алар да юк. Сентябрь җиткәнен көтәм. Шәһәрдә барыр җир, күңел ачардай урыннар күбрәк.

**Динар, 22 яшь:**
– Авылда күңелсез шул, пандемия булгач – бигрәк тә. Үз күңелебезне үзебез күрергә тырышабыз. Яшьләр, җыелып, дискотекалар оештырабыз, авылларга йөрибез. Авылларда яшьләр күбрәк һәм күңеллерәк. Әмәкәйдә, Карамалыда кеше күп. Мөслимдә кеше саны кимеде, элек күбрәк иде. Хәзер бит яшьләргә җыелыр урыннар да күбрәк, парк-скверлар саны артты, бәлки, шуңа кеше аз кебек тоеладыр. Гадәттә, дуслар белән сөйләшеп утырабыз. Атнага бер булса да, шашлык я купаты пешереп, сыйланабыз. Яшьләр өчен төнлә дә эшләрлек берәр кафе ачсыннар иде.

**Ләйсән, 27 яшь:**
– Шәһәр кешесе ял көннәрендә бакчага бара, ә авыл кешесенең бөтен җәе бакчада үтә бугай. Ялларда мин сәүдә үзәкләрендә йөрергә яратам. Кызым белән кафега барабыз, паркка велосипедта йөрергә чыгабыз, һава сулыйбыз. Кич, гадәттә, кино карыйм, яхшы фильмнар яратам.

**Регина, 17 яшь:**
– Көн саен кич чыгабыз. Машинада йөрибез, җырлар тыңлыйбыз. Күрше-тирә авылларга барабыз, анда күңеллерәк. Яңа кешеләр белән танышам, яңа дуслар табам. Аралашу – үзе рәхәт! Кышын салкын менә, ә барыр урын юк. Әле, көннәр суытса да, җәй дәвам итә. Каникулның соңгы көннәре. Вакытны әти-әни янында рәхәт итеп үткәреп калырга тырышабыз.

**Яшьләр белән Римма Афзалова аралашты.**



Фото – Динар Нуретдиновның шәхси архивыннан.

«Авыл утлары»
№ 60 (11312) | **19 август** 2020 ел

Яңалыкларны беренче булып
**www.muslumirc.ru** сайтында укыгыз

# Энгель Әмирович

Үз вакытында Мөслим районы мәгариф бүлеге мөдире, безнең төбәктә беренче кечке мәктәп ачып, йөзләгән райондашларга урта белем бирүне оештырган Әмир Гәрәевнең уртанчы улы ул.

ТАССРга – 100 ел

**Якын тирәдә аны белмәгән, аны күрмәгән, аның турында ишетмәгән кеше юктыр. Булса да, андыйларны санарга ике кул һәм сыңар аяк бармаклары да җитәр. Чөнки район пионер оешмасыннан башлап, редакциядә, райкомда, райисполкомда, хакимияттә, аучылар җәмгыятендә хезмәт итеп, хәтта шәхси эшмәкәр буларак районыбыз тормышында онытылмаслык эз калдырды. Август ае – аның ае. Искә алыйк! Түбәндә аның рәсми эше белән бәйләнмәгән, әмма аның холкын, дөньяга карашын ачып салган ике эпизод белән танышып китик.**

**Ата үрдәк**

Мөслим районы оешкач, Сарманнан кайтып "Авыл утлары"на нигез салган көннәрдә район гәҗитенең фотокорреспонденты булып эшли башлады ул. Беренче мәртәбә аның белән якыннан шул вакытта таныштым. Абыйсы Гегель белән параллель сыйныфларда укыдык. Мәктәптә ул иң алдынгы, алгебра, геометрия һәм тригонометрия фәннәрен укыткан Зәки Ханнанович Әлиевнең яраткан укучыларыннан саналды.

Энгель, әтисе кебек, бик тотнаклы булды. Һәр кеше белән уртак тел табарга кирәк булган ачкычлары, әйтерсең, бер чемоданга сыеп бетмәс. Бик тере: кирәк әйберен табу, алдында туган проблемасын хәл итү өчен сәләте булган кеше белән танышуны ике дә уйламый – "ә" дигәнче таныша да куя. Кирәк булса, сине дә таныштыра.

Коллективның акчасыз утырган көннәре иде. Ул эшкә урнашкач атна-ун көн узмагандыр, редакция бинасының бер почмагында фотолаборатория оештырды да, кирәк кешеләрне үз фотоаппараты белән карточкага төшереп, үз плёнкалары һәм химикатлары белән эшкәрткәч, Казанга, цинкографиягә җибәрә башлады.

**Дөньяга аучы булып туган кебек**

1965 елның октябрь башларында минем хәләл җефетне роддомга озатып куйганны каяндыр һәм ничектер ишетеп, Энгель Әмирович безнең өйгә ике мылтык асып килеп керде. Исәнләшү белән үк:

– Марсель Галиәкбәрович, әйдәгез Мухан әрәмәсенә генә үрдәккә чыгып кайтыйк. Әгәр дә ата үрдәк атып төшерсәк, иптәшегез малай алып кайтыр. Әгәр дә ана үрдәк булса, кыз бала өйгә кайтыр. Әгәр инде икесен дә атып төшерсәк, игезәкләр туар. Кем булса да, икесе дә таза булырлар. Ике мылтыкның берсе – сезнеке. Әйдәгез, көн яктысында йөреп кайтыйк, – диде.

Киттек. Бахшай тирәләрен әйләнеп байтак кына йөргәч, Энгель Әмирович безгә таба очып килгән ике үрдәкнең берсен атып төшерде. Бичара ата үрдәк булып чыкты...

...Өйгә кайткач роддомнан якты дөньяга малай килгәнлеге турында шалтыраттылар.

**Дүртенче "Пли!"**

Академиядә стажировка узган вакытта кышкы каникулга кайткач, Фоат Миңнеәхмәтович белән икебезгә ак халат, ак башлык кигертеп, аучы алып чыгып китте. Өчебез дә – чаңгыда: Энгель Әмировичнеке кыска, киң – чын аучы чаңгысы. Комбайннарда кулланыла торган тапшыру каешын кискәләп, тарайтып, ныклап беркетеп куйган: аяк киеменә момент кияргә һәм момент салырга көйләнгән. Ә безнеке тар, озын, тимер крепление белән. Өчебез дә таяксыз, аның урынына өчебездә дә мылтык бар.

Озын төн буе яуган кар без юлга чыкканда да туктамаган иде. Җитмәсә, бөтен тирәякны томан каплаган: биш-алты адымда торган кеше күренми.

– Боз өстеннән карга төренгән Ык буйлап Бишнарат тегермәненә кадәр баргач, Иске Авыл тавына менәрбез, – диде командир, безне туктатып. – Ау өчен бер дигән погода бүген. Йомшак кар өстеннән барганда бер шыгырдаган тавыш та чыкмый. Монысы бик әйбәт. Тик сез генә кычкырып сөйләшмәгез! Спектакль куярга бармыйбыз – чамалагыз!

Кузгалдык. Беренче булып Энгель Әмирович үзе атлый. Аның артыннан мин сөйрәләм. Алай-болай безгә ияреп аптыраткан куяннар булса, атарга дип, минем артка Фоат Миңнеәхмәтович басты. Араларыбыз 4-5 метрлар чамасы булыр.

Гөнаһ шомлыгы, Ташлыкка җиткәндә Энгель Әмирович күздән югалды. Туктап, Фоат Миңнеәхмәтовичка дәштем.

– Я берәр куян, я төлке күргәндер. Тавыш чыгармыйча артларыннан шыырт кына китүе дә бик мөмкин.

Шулай да "Энгель Әмирович, син кайда?" – дип кычкырдык. Җавап бирүче булмады. Берничә адым алга атлагач, кар өстендә кыймылдаган шәүлә күренде.

– Мин монда! – дип тавыш бирде шәүлә.

Тагын бераз алга шуышкач, шәүләнең бүреген һәм иңсәләрен күрдек.

– Миңа якынаймагыз! – дип тагын кычкырды ул. – Ату сез дә чумарсыз!

Бу сүзләрне әйтеп бетергәндә үк аның гәүдәсе әкренләп суга бата башлаган иде. Тагын кинәт калкып чыкты.

– Менә сыңар чаңгы. Миңа чыгарга булышырсыз! – дип, безгә бер чаңгысын сузды.

– Икенчесе кайда?

– Анысы аякта калды. Шуңа басып торам ич... Аякны ычкындырсаң, ул агып китәчәк...

Тырыша торгач Энгель Әмировичны вещмешогы, мылтыгы һәм икенче чаңгысы белән карлы-бозлы судан тартып чыгардык.

– Ташлыкта агым көчле икәнен дә, бозның юка икәнен дә беләм, югыйсә... Ну, килеп җиткәнемне сизмәдем, – дип, аклангандай, үзенә-үзе сукранды командир.

Бераз тын алыйк дип басып торган арада аның юеш киемнәре боз булып шалтырап катты. Әрәмә эченә кереп тиз генә корыган чыбык-чабык җыйнап өйдек тә учак яктык. Ул ныклап яна башлагач, безнең командир башта киемнәрен җефетте, аннары, мондый очракта мәҗбүри булып саналган (үзенә ашыгыч ярдәм күрсәтү йөзеннән булырга кирәк) рюмкасын бушатты да (без дә авыз күтәреп тормадык) соңгы оекбашына кадәр чишенеп, үзе дә кипшерде, киемнәрен дә киптерде. Дөресен генә әйткәндә, салкында бу кадәр нык чыныккан, ЧП шартларында үзенә үзе ашыгыч ярдәм күрсәтеп, тиз арада нормаль хәленә кайта алган башка кешене танышларым арасында күргәнем юк иде. Әгәр аның урынында Фоат белән мин батсак, икебезне дә "скорый" алып китәр иде. Мондый карлы буранда, җитмәсә, Ык өстендә безне таба алса әле. Ә таба алмаса? Энгель Әмировичның юеш киеме кебек шакырдап катарсың...

**(Ахыры алдагы саннарда).**

**Марсель Вәлитов.**

**Мәскәү.**

## Һава транспортын үз итсәң

Кулланучыга

**Россия Федерациясе баш дәүләт санитар табибы тарафыннан илебезгә һава транспорты белән килү тәртибен көйләүче карарларга үзгәрешләр кертелде. Әлеге кагыйдәләр пассажирларны алып кайтучы һәм ил территориясенә килүче даими рейсларга кагыла.**

2020нче елның 27 июлендәге 22 санлы карарда каралганча, Россия Федерациясе территориясендәге пунктка юнәлүче һава судносына утырганда, шул исәптән транзит йөрү максатында, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затларның үзләре белән ПЦР ысулы белән материалны ковид-19га лаборатор тикшерүнең тискәре нәтиҗәсен раслаучы медицина документлары (рус яисә инглиз телендә) булырга тиеш. Документ бу телләрдә булмаса, әлеге медицина документын биргән илнең рәсми телендә дә ярый, әмма рус теленә тәрҗемә ителгән һәм консуллыкта расланган булу зарур.

Материал Россия Федерациясе территориясенә килүгә кадәр өч календарь көн эчендә алынган булу мөһим. Илебезгә кергәнче чит ил гражданнары Россия Федерациясе территориясенә килүче анкетасын тутырачак.

Һава транспорты белән Россия Федерациясе территориясенә килүче Россия Федерациясе гражданнары очышка кадәр (билет алганда, әмма рейска теркәлгәнче) шулай ук анкета һәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталындагы формасын тутырырга бурычлы.

Россия Федерациясе территориясенә килгән көннән өч календарь көн дәвамында Россия гражданнары ПЦР ысулы белән ковид-19га лаборатор тикшерү үтәргә һәм тикшерү нәтиҗәсе турындагы мәгълүматны дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталындагы махсус формага урнаштырырга тиеш. Самолеттан төшкәннән соң үндүрт календарь көн эчендә сәламәтлеге начарланган очракта гражданнар медицина оешмасына бармыйча гына медицина ярдәме сорап мөрәҗәгать итәргә бурычлы.

Хезмәт эшчәнлеге алып бару максатында килүче чит ил гражданнары әлеккечә 14 календарь көн дәвамында изоляция буенча таләпләрне үтәргә тиеш. Әлеге карар 1 августта гамәлгә керде.

**Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең ТР буенча идарәсе.**

## Туаланма пенсиягә тәэсир итми

Пенсия фонды

**Республикада социаль челтәрләрдә, пабликларда мәгълүмат урнаштыру юлы белән мошенниклык гамәлләре күзәтелә. Янәсе 3 яшькә кадәр һәм 3 яшьтән 16 яшькә кадәр балалар өчен түләүләр шул суммага гражданнарның тупланма пенсиясен киметә. Бу дөрес түгел.**

Пенсия Татарстан Республикасы буенча Россия Пенсия фонды бүлекчәсе исегезгә төшерә: 3 яшькә кадәр һәм 3 яшьтән 16 яшькә кадәр балалар өчен өстәмә түләүләргә акча өстәмә рәвештә федераль бюджеттан бүленеп бирелә һәм гражданның тупланма пенсиясе күләменә тәэсир итми. Мондый мәгълүматны мошенниклар тарата.

Барлык шикле очракларда да татарстанлылар Россия Пенсия фондының контакт-үзәгенә мөрәҗәгать итә ала.

**Мөслим районында клиентлар белән эшләү хезмәте.**

## Ирегеннән мәхрүм ителде

Кеше һәм закон

**Явыз ният белән кеше сәламәтлегенә зыян салган.**

Район прокуратурасы 29 яшьлек якташыбызга карата җинаять эше буенча дәүләт гаепләвен яклап чыкты. Суд аны РФ Җинаятьләр кодексының 112 маддәсе 2 бүлеге "д" пунктында каралган җинаять кылуда гаепле дип тапты.

Суд утырышында билгеләнгәнчә, бу хәл 2020нче елның 1 гыйнварында 23.00 сәгатьләр тирәсендә Мөслим авылының Хәбибуллин урамындагы бер участогы янында була. Гаепләнүче явыз ният белән зыян күрүчегә тән җәрәхәте ясый: йодрыгы белән йөзенә суга. Нәтиҗәдә зыян күрүченең яңак сөяге сына.

Гаепләнүче үз гаебен өлешчә генә таныды һәм килгән зыянны каплады. Суд, гаепләнүченең гамәлләрендә рецидив булуын һәм дәүләт гаепләүчесенең позициясен исәпкә алып, гаепләнүчене гаепле дип тапты һәм ике ел сынау вакыты белән аны шартлы рәвештә ике елга ирегеннән мәхрүм итте.

Суд хөкеме үз көченә керде.

**Район прокуратурасы.**

# Французча әзерләнгән тавык ите

Аш-су

**Тавык итеннән әллә нәрсәләр пешерергә була. "Французча ит" не яратмаган кеше юктыр. Кафе-рестораннарда бу ризыкны яратып ашыйлар. Өй шартларында әзерләнгәне аеруча тәмле була. Мөслимнән Айсылу Латыйпова үз рецепты белән бүлешә.**


Фото – А. Латыйпованың гаилә архивыннан.

Кирәкле ингредиентлар: 500 грамм тавыкның түш ите, 100 грамм сыр, дүрт аш калагы каймак, биш аш калагы майонез, 250 грамм шампиньон гөмбәсе, уртача зурлыктагы бер суган, 100 грамм сөт өсте (сливки), тәменчә тоз һәм борыч. Кыздырыр өчен акмай кирәк булачак.

Әзерләү тәртибе: тавыкның түш итен кисеп алабыз һәм чүкеч белән төябез, тозлыйбыз, өстенә сөт өсте салабыз һәм ярты сәгатькә салкын урынга куябыз. Шампиньоннарны турыйбыз һәм суган белән акмайда кыздырабыз. Тавык итен майлы табага тезәбез, өстенә гөмбә белән суганны салабыз һәм өстенә каймак-майонез катнашмасын агызабыз. Өстенә, угычтан чыгарып, сыр сибәбез. Ризык 180 градуска кадәр җылытылган мичтә 30-35 минут эчендә пешеп чыгачак.

Тәмле булсын!

**Рубриканы Лилия Шәймиева алып бара.**

## Котлыйбыз!

Бу көннәрдә районыбызда яшәүче өлкән буын вәкилләре, тыл һәм хезмәт ветераннары **Галимов Мисбах Камай улы** (Сал. Мухан), **Бикмурзина Хашия Вәли кызы** (Күбәк) – 90 яшьлек, **Шәмсетдинова Фәния Әмирҗан кызы** (Баланлы), **Шакирова Фәүзия Сәлим кызы** (Метрәй) – 85 яшьлек, **Әмирова Диләрә Шакир кызы** (Баланлы), **Тимергалиев Муллаһади Хуҗагали улы** (Күбәк) – 80 яшьлек, **Хөсәенова Илгизә Салих кызы** (Мөслим), **Закирова Фәния Солтангәрәй кызы** (Баек), **Нәҗмиева Әнисә Шәехҗан кызы** (Олы Чакмак), **Новикова Вера Ивановна** (Рус Шуган) – 75 яшьлек, **Фәрхетдинова Фәнүзә Габдулла кызы** (Мөслим), **Булавенко Петр Владимирович** (Метрәй), **Асылхуҗина Розалия Сәрвәр кызы** (Октябрь) – 70 яшьлек, **Җиһангирова Флүзә Мизхәт кызы** (Иске Вәрәш), **Магалимова Розалия Әхмәтян кызы** (Иске Вәрәш), **Муминов Хусейн** (Тат. Шуран), **Мостафин Мөдәрис Хәйдәр улы** (Элемтә), **Дәүләтов Васыйл Рифкать улы** (Тойгелде) – 65 яшьлек, **Вәҗиева Нурия Миншәрип кызы** (Мөслим) 60 яшьлек юбилейларын билгеләп үтәләр.

Хөрмәтле юбилярлар! Сезне ихластан истәлекле гомер бәйрәмнәрегез белән тәбриклибез. Сезгә имин тормыш, ныклы сәламәтлек телибез. Якыннарыгызның күңел җылысын, ихтирамын тоеп, кадер-хөрмәттә озын гомер кичерергә язсын. Гаиләләрегездә һәрвакыт муллык һәм бәрәкәт булсын.

**Рамил Муллин,**
**район башлыгы,**
**район Советы рәисе.**
**Илгиз Низамов,**
**район ветераннар советы рәисе.**

## Бәрәңге турында

Файдалы киңәш

**Бәрәңгене алыр алдыннан сабагын чабарга кирәк**

Бәрәңгене казыр алдыннан сабакларын чабып алырга кирәк. Шуннан соң 2-3 атна көтәргә. Сабаклары яшел булып, чапканнан соң ук казый башласаң, бәрәңгенең кабыгы үзеннән-үзе аерыла торган була. Ә кабык нык булырга тиеш. Кабыгы җиңел тешә торган бәрәңге авырулар өчен яхшы җирлек булып тора.

**Алуга ук бәрәңгене базга төшерү – хата**

Бәрәңгене алуга ук базга төшерергә ярамый. Аны берәр складта тотып алырга кирәк, җыйган вакытта дымлы булса, бигрәк тә. Астына салам яки башка дым сеңдерә, һаваны яхшы үткәрә торган берәр нәрсә җәяргә кирәк. Аның өстенә бәрәңге салырга, ләкин катлам зур булмасын, якынча 20-50 см. Әлеге бинада тәрәзәләр, ярыклар булса, бәрәңге яшәрмәс өчен җиңелчә генә салам белән каплап куярга мөмкин. Бәрәңгене казыганнан соң шунда ук орлыкка, ашарга дигәнен аерырга мөмкинлек булса, орлыкка дигәннәрен урамда калдырсаң, яхшы. Төнгелеккә яки яңгыр яуган очракта гына каплап калдырсагыз була. Тышта алар әйбәтрәк кибә, яшәрә һәм язга кадәр күпкә яхшырак саклаexistsначак.

Актив җилләтү булмаган очракта, бәрәңгеләрне җир өстендә, мәсәлән, келәттә бер айга якын сакларга мөмкин. Билгеле, суыклар вакытында аны берәр нәрсә белән каплап, күзәтеп торырга кирәк. Бәрәңге сулый, үз-үзен җылытып тора. Тышта суык булганда бәрәңге үзен 5-10 градуска кадәр җылыта ала.

**Саклар алдыннан әзерлек**

Базга төшерер алдыннан бәрәңгене әйбәтләп киптерергә һәм начарларыннан аерырга кирәк. Бәрәңгене алуга ук түгел, ә берәр ай келәттә киптергән соң араларга киңәш ителә. Казып алган вакытта фитофторозлы бәрәңгеләрдә кечкенә бер тап кына булырга мөмкин, аны күреп алу кыен. Бер айдан соң авыру бүлбеләрдә фитофтороз инде күренеп торачак. Шунда ук аралап куйсаң, базда черү булмаячак. Бәрәңгедән туфракның яхшы коелуы аның әйбәт кипкән булуын күрсәтә.

**Бәрәңге базын елга бер чистартырга кирәк**

Базны елга бер чистартырга, җирен алырга кирәк. Гөмбә спораларын бетерү өчен бакыр купоросы белән эшкәртергә мөмкин. Җилләтү өчен баздан урамга чыгарылган торба булуы кирәк. Чөнки бәрәңге һәрвакыт сулый, җылылык бүлеп чыгара. Әлеге җылылыкны чыгармасаң, бәрәңге вакытыннан алда үрергә мөмкин. Саклау барышында бәрәңгене күзәтеп торырга, чери башлаганнарын ала барырга кирәк.

Баз торак йорт подвалында түгел, ә кайдадыр читтә урнашкан булса, фумигация ясарга мөмкин. Моның өчен сатуда махсус шашкалар бар. Агулы төтен бинада бөтен зарарлы микробларны юкка чыгара. Черү куркынычы зур булган очракта бәрәңгене базга төшергәннән соң да фумигация ясарга мөмкин. Ләкин бу очракта әлеге препаратның күрсәтмәләрен яхшылап укырга кирәк.

## Кыскача

**ДАИ**

Юл һәлакәтләрен кисәтү максатында 11-18 август көннәрендә "Автобус" профилактик операциясе узды."Чара барышында пассажирларны законсыз ташу фактларына юл куймау, лицензия таләпләрен үтәү, автобусларның техник торышы һәм машина йөртүчеләрнең куелган таләпләргә туры килү-килмәве тикшерелде", – ди ДАИ хезмәткәрләре. Җирлегебездә 35 автобус бар, шуларның 13е мәктәп укучыларын йөртә. Ел башыннан 17 автобус йөртүчегә һәм техниканы юл линиясенә чыгарган җаваплы өч хезмәткәргә административ беркетмә төзелгән. "Автобус" операциясе барышында мәктәп автобусларын тикшерүгә аерым игътибар биреледе. Кимчелекләрне уку елы башланганчы төзәтү бурычы куелды.

**Иминлек**

Җирлегебездәге күпбалалы гаиләләргә, өлкәннәргә, ялгыз яшәүче һәм физик мөмкинлекләре чикле кешеләрнең торакларына янгын турында хәбәр бирүче җайланмалар урнаштыру дәвам итә. Узган атнада 22 гаиләгә 88 автоном җайланма куелды. Янгын куркынычсызлыгы таләпләренең үтәлешен тикшерү, кагыйдәләрне аңлату максатыннан Мөслим һәм Сарман районнары буенча күзәтчелек эшчәнлеге бүлеге автоном җайланмалар куелган йортларга даими рейдлар үткәрә.

**Сәламәтлек**

17 августтан район үзәк хастаханәсендә планлы госпитализация башланды. Атна башыннан диспансерлаштыру эше дә бара. Диспансерлаштыру кысаларында Яр Чаллы шәһәреннән күчмә маммограф килүе көтелә. Аның тәгәл вакытын участок табибларыннан белешергә була. Маммографияне план буенча 730 хатын-кыз үтәргә тиеш. Бүгенгә аларның 430ы гына маммография тикшерүе узган. "17 августтан Татарстанда коронавирустан саклану максатында перчаткалар кию мәҗбүри түгел. Бу хакта хөкүмәт йортында узган республика киңәшмәсендә хәбәр ителде. Учреждениеләрдә санитар-гигиена таләпләрен үтәү мәҗбүри шарт булып кала. Хастаханәгә битлек белән керү шарт", – ди районның баш табибы Рамил Морзаханов.

# Үткәннән бер мизгел


Мәлләтамак урта мәктәбе коллективы. 1970 нче еллар. Фотоны Мәлләтамактан Рәмзия Бакыева тәкъдим итте.

# Котлыйбыз!



Кадерле әниебез **Нәҗипова Гөлфия Хантимер кызының** 20 август көнне гомер бәйрәме – 50 яшьлек юбилее. Әниебез, Түбән Кама төзелеш көллиятен тәмамлап кайткач, Тат. Бүләр авылында әтиебез Рифат белән гаилә кора. Шул вакыттан алып, бүгенгәчә "Сәйлән" балалар бакчасында пешекче булып эшли.

Әниебез оста пешекче буларак билгеле. Әлеге өлкәдә 30 елга якын стажы булган әниемнең ризыклары беркемне дә битараф калдырмый. Шуның өстенә әниебез тегү остасы да әле. Без кечкенә чакта энем белән миңа сәхнә күлмәкләре тегә. Әниебез хатын-кызга хас булган барлык сыйфатларны да үзенә туплаган. Аның йөзеннән нур бөркелә. Ул безне кешелекле, рәхмәтле, мәрхәмәтле булырга өйрәтте. Гаиләбезнең җылы учагын саклаучы әниебез белән әтиебез һәрчак безгә үрнәк.

Сөекле әниебез! Эти белән син – җир йөзендә безнең иң кадерле кешеләребез. Син булганга болытлы көннәр дә кояшлы, салкын бураннар да әкияттәгедәй сихри, чөнки синең күңелеңнән нур бөркелә. Безне һәрчак шулай куандырып, кайткан саен тәмле сыең, назлы сүзләрең белән иркәләп, әтиебез белән бергә-бергә озак еллар сау-сәламәт булып, күңел тынычлыгы белән, бәхет-шатлыкта, кайгы күрми яшәвеңне телибез! Без сине бик яратабыз!

**Иң изге теләкләр белән укытучы кызың Эльвина, Ерак Көнчыгышта Хәрби Диңгез флотында хезмәт куйган улың Зирәк, 6 сыйныфта укучы кызың Адилә һәм яраткан тормыш иптәшең Рифат.**

# Котлыйбыз!



Тат. Бүләр авылында яшәүче кадерле әтиебез **Нуриев Мәхмүт Мәкъсут улына** 18 августта 65 яшь тулды. Әтиле йортны нурлы йорт дип юкка гына әйтмиләр. Әтиле нигез бәхетле, бәрәкәтле була.

Газиз әтиебез! Син – безнең яклаучыбыз, саклаучыбыз да. Без – өч кызыңны җиһ-давыл тидермичә, кадерләп үстереп, олы тормыш юлына бастырганың өчен чиксез рәхмәтлебез. Әниебез Альбина белән безгә биргән киңәшләрегез һәм күркәм тәрбиягез гомер агышында үз юлыбызны табарга, алга куйган хыял-максатларга ирешергә ярдәм итте. Әтиебез! Туган көнең котлы булсын! Олы җаныңда һәрберебезнең борчу-шатлыгына да урын бар. Син булганда без үзебезне ышанычлы калкан артында итеп хис итәбез. Миһербанлы йөрәгең беркайчан да тибүдән туктамасын! Авырмыйча, сау-сәламәт булып, әниебез Альбина белән алга таба да тигезлектә, оныклар өчен яраткан әби-бабай булып яшәргә язсын! Картлык көннәрегез шатлыкта, тигезлектә генә үтсен!

*Син җирдәге һәр нәрсәгә гашыйк,*
*Гашыйк таңга, зәңгәр кичләргә.*
*Син яшисең шушы матурлыкка*
*Тагын матур бер ямь өстәргә.*

**Кызларың Диләрә, Лилия, Элина, өч киявең, әниебез Альбина, биш оныгың.**

# Котлыйбыз!



Мөслимдә яшәүче әниебез **Фәрхетдинова Фәнүзә Габдулла кызына** 18 августта – 70 яшь.

Кадерлебез! Сине юбилееӊ белән тәбриклибез. Тормыш көзгебез булып, барлыгың белән сөендереп яшәсәң иде! Алдагы көннәреңдә дә сәламәт булып, бәрәкәтле гомер кичер! Син булганда көннәребез кояшлы, тормыш матур, әниебез!

*Бүген дә гел безне кайгыртып,*
*Җан атып, "без" диеп яшисең.*
*Бар галәм беләдер: безгә син –*
*Иң газиз, иң якын кешесең.*

**Әтиебез Мифтахетдин, балаларың Ленар-Гөлнара, Рушан-Гүзәл, Рунар-Гөлназ, оныкларың Алмаз, Эльвина, Ислам, Азамат, Азиза, Данил.**

**Мөслим телевидениесе**
тапшыруларын чәршәмбе һәм җомга көннәрендә карарга була. Башлана 19.00 сәгатьтә. Ютубта Мөслим тапшырулары "Муслюмовское телевидение" каналында чыга.
Реклама 16+

**"Мөслим-информ"га татар һәм рус телләрен яхшы белүче корреспондентлар кирәк. Т. 2-55-00.**
Реклама

## Рәхмәтебез

29 июль көнне гаиләбезгә зур кайгы килде. 39 ел бергә тату гомер иткән тормыш иптәшем, балаларыбыз, оныкларыбызның яраткан бабалары, газиз әтиләре **Кәримов Сәгадәт Вахит улының** йөрәге тибүдән туктады. Ул Аллаһ хозурына күчте.

Кайгыбызны уртаклашкан, мәрхүмне җирләүдә булышкан һәм матди, рухи яктан ярдәм күрсәткән дин кардәшләребезгә, барлык туганнарга, дусларыбызга, хезмәттәшләребезгә, Баланлы авылы халкына зур рәхмәтебезне җиткерәсебез килә.

Кылган игелекләрегезне Аллаһы Тәгалә кабул итеп, әҗер-савапларын бирсен! Йортларыгызга кайгы-хәсрәт килмәсен, исән-имин яшәгез! Амин.

**Мәрхүмнең тормыш иптәше, балалары, оныклары.**

Реклама

ХӘТЕР ТАШЛАРЫ, ЧАРДУГАННАР. Фәтхуллин ур., 6. Ялсыз эшлибез. Т.2-38-46, 8-927-451-27-10. Реклама

**ПЛАСТИК тәрәзәләр**
**8(904) 670-71-71**
– Заводские окна
– Алюминиевые двери
– Ламинация
– Балконы
– Жалюзи
– Откосы
– Гарантия
REHAU
HARISS пластиковые окна
Реклама

**ОКНА «Бәхетле»**
5 -ое окно в подарок у нас
*Расширение оконного проема
*Установка откосов
*Рулонные шторы
*Жалюзи
скидка до 30%
Отлив, подоконник, москитная сетка, замер БЕСПЛАТНО
Рассрочка без участия банка*
*Рассрочку предоставляет ООО «Бәхетле»
8-963-902-0000
Реклама

ОКНА МЕЧТЫ
**Закажи у нас!** Будь уверен в своем выборе!
ВСЕ ЭТО МОЖНО ЗАКАЗАТЬ У НАС:
• Окна ПВХ и Евродерево
• Балконы под ключ
• Витражи и двери из алюминия и ПВХ
• Ворота • рольставни • входные группы
Закажи у профессионалов. Гарантия 10 лет
8-939-393-48-48, 8-917-879-61-62
РАССРОЧКА БЕЗ БАНКА
*рассрочку предоставляет ООО «РИКАМ-СТРОЙ НЧ» Реклама

БУ УРЫНДА СИНЕҢ БЕЛДЕРҮ БУЛЫРГА МӨМКИН ИДЕ! Реклама

Туйлар, юбилейларга – *БАНКЕТ ЗАЛЫ.* Т.8-927-473-80-84. Реклама

**ОКНА И ДВЕРИ**
– откосы – рулонные шторы
– жалюзи – москитные сетки
**Скидки до 50 %**
**Т.8-937-477-16-16.**
Рассрочка без участия банка*
* Рассрочку предоставляет ИП Усманова Диана Рамзиловна.
Реклама

## Сатыла

### терлек, кош-корт

▶ **Маточный бройлер.** Доставка. Т.8-939-330-27-66.

▶ **Тәмле сөтле савым кәҗәләре,** каплатылган яшь кәҗәләр. Т.8-919-685-40-23.

▶ **Суярдай яшь бройлер** чебиләре китерәбез. Т.8-917-267-14-28. Гөлгенә.

▶ **23 августта үгез ите** сатабыз. Катмыш авылы. Илфак. Т.8-917-876-67-45, 8-939-347-68-25.

▶ **Эре бройлер,** үскән каз, үрдәк, мулард, яшь тавыклар китереп бирәбез. Т.8-987-419-38-11, 8-939-319-85-06, 8-960-077-65-76.

▶ **Бозаулар.** Т.8-960-079-78-44, 8-937-777-20-88.

▶ **Кызыл тавык,** үрдәк, мулард. Т.8-917-267-14-28. Гөлгенә.

### йорт

▶ **Тойгелдедә йорт сатыла.** Т.8-986-721-62-07.

### төрлесеннән

▶ **Арпа, бодай, салам, вика.** Т.8-986-929-97-52.

▶ **Әндереш балы.** Т.3-52-09.

▶ **Кырынтаудан бал.** Кәрәзле бал. Китереп бирү мөмкин. Т.8-917-281-45-82.

▶ **Бодай, салам.** Т.8-958-622-01-72.

▶ **Ярылган утын.** Т.8-904-675-75-36.

## Хезмәт күрсәтәбез

▶ **Ремонт холодильников.** Т.8-951-067-74-13.

▶ **Ремонт телевизоров.** Т.8-950-324-08-91.

▶ **Ремонт холодильников,** стиральных машин, кондиционеров. Т.8-917-895-15-54, 8-927-476-86-86.

▶ **Йомшак мебель** тышлыйбыз. Т.8-906-117-07-14.

▶ **"Газель".** Грузоперевозка. Т.8-917-266-50-60, 8-927-473-80-84.

## Сатып алам

▶ **Үгез, сыер ите.** Т.8-927-966-55-53.

▶ **Сыер ите.** Т.8-963-135-33-71.

▶ **Сыер, үгез:** итләтә, терелэй. Т.8-987-135-03-47, 8-927-940-31-01.

▶ **КРС мясом.** Т.8-917-435-41-04.

▶ **Терелэй мал.** Т.8-987-049-73-71.

БУ УРЫНДА СЕЗНЕҢ БЕЛДЕРҮ БУЛЫРГА МӨМКИН ИДЕ! Реклама

Яңа Усы авыл җирлеге советы һәм башкарма комитеты, җирлекнең ветераннар советы, эниләре **Пискунова Ольга Сафроновна** вафат булу сәбәпле, балаларының, якыннарының һәм туганнарының авыр кайгысын уртаклаша.

***

Мөслим лицее коллективы, профсоюз комитеты, лаеклы ялдагы укытучы **Салихова Әнисә Каюм кызы** вафат булу сәбәпле, балаларының, туганнарының, якыннарының авыр кайгысын уртаклаша. Бу кайгыны кичерүдә сабырлык тели.

**Гамәлгә куючы: "ТАТМЕДИА" АҖ.** **www.muslumirc.ru** **Реклама хезмәте телефоны: (85556) 2-43-05.**

Авыл утлары
Мөслим районы газетасы
"ТАТМЕДИА" АҖ филиалы директоры – баш редактор **Р. Р. Афзалова.** Тел.: 2-55-00.

**Редакция адресы:** 423970, Татарстан, Мөслим районы, Мөслим авылы, Пушкин ур., 43.
**Электрон адрес:** muslimau@rambler.ru
**Телефоннар:** бухгалтерия – 2-39-76, реклама, заказлар – 2-43-05.
**Нәшир:** АО "ТАТМЕДИА". 420097, Казан шәһәре, Академическая ур., 2.

Газета элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникация сферасында күзәтчелек буенча Федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсендә ПИ №ТУ16-01027 номерлы таныклык белән 2013 нче елның 16 маенда теркәлде.
Газета "Глагол" ҖЧҖ басылды.
Адресы: 423800, ТР, Яр Чаллы шәһәре, Әлмәт тракты, 10 йорт, 3 бина.
Басарга кул куелды 18.08.2020, график буенча – 19.00, фактта – 16.54.
«Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.

ТАТ МЕДИА
**Тираж – 2395 данә.**

Редакция фикере һәрвакытта да авторлар фикере белән аваздаш булмаска мөмкин.
Редакциянең рәсми оешмаларда яклаучы булу мөмкинлеге юк.
**Кульязмаларга бәяләмә язылмый һәм алар кире кайтарылмый.**
Реклама-игъланнардагы мәгълүматның дөреслеге өчен реклама бирүчеләр үзләре җаваплы.

© Материаллар редакциянең язма рөхсәте белән генә күчереп бастырылырга мөмкин.

Газета татар телендә атнага ике тапкыр – чәршәмбе һәм җомга көннәрендә, рус телендә атнага бер тапкыр – җомга көнне чыга.
Заказ №1663.
Язылу индексы – П9418.
Бәясе ирекле.
16+